ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2026 Олы Кайбыч ав. № 175

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм территорияләр объектларына якын урнашкан территорияләрнең чикләрен билгеләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында»1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясына ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР ИТӘ:**

1. Кайбыч муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен түбәндәгечә билгеләргә:

1) мәгариф оешмалары (өстәмә белем бирү, өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан тыш) карамагындагы һәм (яисә) файдалануындагы биналар, корылмалардан - 35 метр;

2) балигъ булмаганнарны укытуны гамәлгә ашыручы оешмалар карамагындагы һәм (яисә) файдалануындагы биналар, корылмалардан - 35 метр;

3) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлек буенча медицина эшчәнлеге төрләреннән тыш, оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә юридик затлар һәм эшчәнлекнең төп (устав) төре буларак медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыручы яисә төп (устав) эшчәнлеге белән беррәттән медицина эшчәнлеген Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән лицензия нигезендә гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарлар карамагында һәм (яисә) файдалануында булган биналар, корылмалардан - 15 метр;

4) билгеләнгән тәртиптә теркәлгән күчемсез милек һәм хокук объектлары булган

спорт корылмаларыннан - 20 метр;

5) вокзаллардан - 20 метр;

6) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган югары хәвефлелек чыганаклары урнашкан урыннардан-50 метр.

2. Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районында алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм территорияләр объектларына якын чикләрне билгеләү турында» 2013 елның 24 апрелендәге 273 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://kaybici.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары О.Д. Макаровага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026е.26.03. 175 номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләрнең кайбер оешмаларына һәм объектларына якын чикләрне билгеләү тәртибе**

1. Әлеге тәртип территорияләрендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган оешмалардан һәм (яисә) объектлардан Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендәге стационар сәүдә объектларына һәм (яисә) җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтә торган объектларга кадәр араларны билгеләүнең бердәм кагыйдәләрен билгели.

2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

2.1. Аерымланган территория-чикләре киртә (ясалма объектлар) белән билгеләнгән территория, ул әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән оешмалар һәм (яисә) объектлар урнашкан бинага (төзелешкә, корылмага) якын урнашкан.

2.2. Тротуар - җәяүлеләр хәрәкәте өчен билгеләнгән һәм машина йөрү өлешенә яисә велосипед юлына тоташкан яисә алардан газон белән аерылган юл элементы.

2.3. Җәяүлеләр юлы - җәяүлеләр хәрәкәте өчен ясалган яисә җайлаштырылган җир полосасы, яисә ясалма корылма өслеге.

2.4. Җәяүлеләр кичүе - разметка белән билгеләнгән юл өлеше участогы.

2.5. Җәяүлеләр зонасы - башы һәм ахыры махсус билгеләр белән билгеләнгән, җәяүлеләр хәрәкәт өчен билгеләнгән территория.

3. Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләре араны метрлап билгеләү юлы белән түбәндәге тәртиптә билгеләнә:

3.1. Аерымланган территория булганда - аерымланган территориягә килүчеләр өчен керү урыныннан алып стационар сәүдә объектына һәм (яисә) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтә торган объектка керүчеләр өчен керү урынына кадәр.

3.2. Аерымланган территория булмаганда - әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән оешмалар һәм (яисә) объектлар урнашкан бинага (корылмага, бинага, урынга) килүчеләр өчен керү урыныннан алып стационар сәүдә объектына һәм (яисә) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтә торган объектка килүчеләр керү урынына кадәр.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән объектлардан янәшәдәге территорияләр чикләренә кадәр ара тротуарлар яисә җәяүлеләр юллары (алар булмаганда - юл кырыйлары, велосипед юллары, машина үтә торган юл кырыйлары буйлап), җәяүлеләр кичүләре буйлап иң кыска ара буенча үлчәнә. Җәяүлеләр зонасын машина йөрү өлеше белән кисешкәндә, ара якындагы җәяүлеләр кичүе буенча үлчәнә.

Тротуарлар, җәяүлеләр юллары, җәяүлеләр кичүләре буендагы ара әлеге объектларның уртасыннан (үзәк сызыгыннан) үлчәнә.

5. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән объектлар бинасында (төзелешендә, корылмасында, урынында) килүчеләр өчен бердән артык керү урыны булган очракта, янәшәдәге территорияләр чикләренә кадәр ара һәр керү урыныннан билгеләнә.

6. Янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләгәндә янгын сүндерү, биналарга (корылмаларга, бүлмәләргә) һәм аерымланган территориягә запас һәм башка керү юллары исәпкә алынмый.